КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 9 октябрь г.Казань № 816

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 8 апрель, 208 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 декабрь, 1058 нче, 2025 ел, 3 апрель, 195 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы карамагындагы адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 бүлекнең сигезенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

7.2.1 пунктчаның беренче абзацында «, салым түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2.2 пунктчаның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

7.2.3 пунктчада:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«NSI^{t}_{i_{sp}} = \frac{K^{t}_{i_{sp}} + S^{t}_{i_{sp}} + B^{t}_{i_{sp}} + F_{sp} + M_{sp} + Tr_{i} + Os_{i}}{Sq_{i_{sp}}},»;$$

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

7.2.14 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетика юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслауны кертү турында» 2009 ел, 14 декабрь, 854 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 февраль, 111 нче, 2022 ел, 4 июль, 621 нче карарлары белән үзәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының сәнгать-эстетика юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәъдимнәргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.16 пунктта «, салым түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.17 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.18 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«NSI_{i_v}^{t} = \frac{K_i \times m_i \ (S_i + B_i + F + M) \times m_i}{So_i \times 12},»;$$

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.24 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы, 2015 ел, 6 ноябрь, 325 нче, 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче, 2016 ел, 1 март, 127 нче, 2016 ел, 4 июнь, 372 нче, 2017 ел, 12 май, 276 нчы, 2017 ел, 29 июль, 529 нчы, 2017 ел, 28 август, 609 нчы, 2018 ел, 18 июнь, 493 нче, 2018 ел, 12 сентябрь, 773 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1218 нче, 2019 ел, 7 сентябрь, 800 нче, 2019 ел, 16 декабрь, 1154 нче, 2020 ел, 25 август, 731 нче, 2020 ел, 9 октябрь, 915 нче, 2020 ел, 25 декабрь, 1192 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 811 нче, 2021 ел, 25 сентябрь, 914 нче, 2022 ел, 22 гыйнвар, 38 нче, 2022 ел, 17 май, 452 нче, 2022 ел, 27 июнь, 611 нче, 2023 ел, 15 апрель, 471 нче, 2023 ел, 1 август, 927 нче, 2023 ел, 30 август, 1041 нче, 2023 ел, 10 октябрь, 1290 нчы, 2023 ел, 2 декабрь, 1548 нче, 2024 ел, 17 гыйнвар, 17 нче, 2024 ел, 14 февраль, 79 нчы, 2024 ел, 13 сентябрь, 784 нче, 2024 ел, 5 ноябрь, 963 нче, 2025 ел, 30 апрель, 287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FO^{t}_{invf} = (( \sum_{n=1}^{w} \sum_{p=1}^{q} \sum_{f=1}^{s} ((NFZ^{t}_{nvf} - R_{FOT} \times N^{t}_{ifo}) + (R_{FOT} \times KNFZ^{t}_{nvf} \times N^{t}_{ifo})) + \\ + (( \sum_{n=1}^{w} NF^{t}_{nvf} - R_{FOT} - FOT_{op}) \times KNF^{t}_{invf} \times N^{t}_{ifg}) + ((R_{FOT} + FOT_{op}) \times K^{t}_{FOT} \times \\ \times N^{t}_{ifg}) + ((BNSI^{t}_{nvf} \times KNSI^{t}_{invf} + FOT_{op}) \times N^{t}_{ipo} \times D_{gg})) - DD_{ichpy},»;$$

унтугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларын һәм күпюнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 3 сентябрь, 701 нче, 2012 ел, 13 февраль, 111 нче, 2022 ел, 4 июль, 621 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларын һәм күпюнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.16 пунктта «, салым түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.17 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.18 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«NSI^{t}_{i_v} = \frac{K_i \times m_i \ (S_i + B_i + F + M) \times m_i}{So_i \times 12},»;$$

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.24 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 500 нче, 2018 ел, 14 август, 666 нчы, 2021 ел, 2 март, 109 нчы, 2021 ел, 14 июль, 569 нчы, 2023 ел, 6 март, 210 нчы, 2023 ел, 15 сентябрь, 1131 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

унөченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«R_{si} = R_{fot_{obsl}} + K + R_{rem_zd} + R_{rem_im} + R_{obn_im} + R_{vohr},»;$$

егерме өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә һәм дәүләт мөлкәтен карап тотуга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2014 ел, 1 август, 563 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә һәм дәүләт мөлкәтен карап тотуга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«NSI = \frac{(K+F+D+A)}{S_{S_{otap}} \times 12},»;$$

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 июль, 605 нче, 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы, 2018 ел, 3 декабрь, 1077 нче, 2019 ел, 28 декабрь, 1232 нче, 2020 ел, 3 сентябрь, 785 нче, 2022 ел, 5 февраль, 92 нче, 2022 ел, 19 апрель, 370 нче, 2023 ел, 7 сентябрь, 1092 нче, 2024 ел, 24 июль, 591 нче, 2025 ел, 17 июнь, 439 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен карауга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча җирле үзидарә органнары өчен методик тәкъдимнамәләрнең 3 бүлегенең 3.1 пунктындагы беренче абзацында «һәм салым түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатлар мөлкәтен карауга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча җирле үзидарә органнары өчен методик тәкъдимнамәләрнең 3 бүлегенең 3.1 пунктындагы беренче абзацында «һәм салым түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин